

Һади ТАКТАШ

# ТӘҮФЫЙКЛЫ ПЕСИ

Хади ТАКТАШ

# УМНИЦА

Hadi TAKTASH

# MY LOYAL CAT

Hadi TAKTAŞ

# EDEPLİ KEDİ

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

# ТӘҮФЫЙКЛЫ ПЕСИ

ӘБИ

Минем песи гаҗәп хыянәтсез,
Мулла кебек тәүфыйк иясе:
Каймак куясыңмы... ни куйсаң да,
Һич кенә юк инде тиясе.

*

Чүлмәгемне шунда калдырыйм да
Печән бирим малкайларыма...

ПЕСИ

Ә мин, әби җаным, син килгәнче
Менеп төшим чүлмәк янына.
Песи өчен нәрсә, еракмыни
Өстәл белән бүкән арасы.
Азапланып бер дә менәсе юк,
Тик бер генә сикреп аласы.

*

Каймак — тәмле әйбер, каймак өчен
Җанын җуя бик күп песиләр...
Тик уңайсыз шунсы: каймакларын
Тар чүлмәккә сала кешеләр.

*

Менә хәзер әйбәт булып китте.

ЭТ

Йортны саклау, малай, җиңел түгел,
Караклар шул куркып тормыйлар;
Күзеңне дә йомып өлгермисең,
Хәзер бер нәрсәңне урлыйлар!



Кешеләре әле кешеләре,
Мәчеләре тынгы бирмиләр.
Алар сыйланалар, йонлы колакларны,
Ә хуҗалар мине тиргиләр.

*

Чүлмәк харап булды.

## ЭТ

Анда нәрсә?
Берәр карак, ахры, кергәндер...
Юк, качалмас, шайтан алган нәрсә, —
Мине йоклый диеп белгәндер.

*

Каракларның, малай, эзе дә юк,
Кай арада качып киткәннәр?!
Абау, йөзе кара булгырлары,
Сөт чүлмәген харап иткәннәр.

Бу — мәчеләр эше, һичбер шик юк,
Үләт кенә төшсен аларга.

*

Тәмле әйбердер, ахры, — белер өчен
Кирәк, малай, кабып карарга...

*

Әйе, кирәк...
Тәмле, бигрәк тәмле,
Песиләр шул тора беләләр...
Йонлы борыннарны, эшләмичә,
Каймак ашап рәхәт күрәләр...

*

Акбай кәефләнде:
— Ну, каймагы әйбәт икән, —
Диеп мактады.